**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ошторма Юмья авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**05 ноября 2020 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Вильмон авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Вильмон авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Вильмон авылы, Мирная урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йортта гражданнар җыены үткәрү.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән тыш кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Вильмон бистәсендә янгынга каршы кое урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Вильмон авылының урам юл челтәрен карап тоту, җәйге чорда юлларны кардан һәм территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) »?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ошторма Юмья авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ошторма Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.Г. Антонов